СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.04.2024 с. Верхний Услон № 44- 598

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 2020 елның 23 мартындагы 56-638 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 04.06.2020, № 58-673, 14.12.2020 № 4-53, 30.05.2022 № 30-412, 20.03.2023 № 32-431, 21.08.2023 № 36-492, 2023 елның 20 декабрендәге 38-520 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:
«12) әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).»;

1.2. Нигезләмәнең 3.4.1нче пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, яки алар муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый торган документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмау;

1.3. Нигезләмәнең 4.1.3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль

башкарма хакимият органы билгеләгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетаны;

1.4. Нигезләмәнең 8.1.1 пунктындагы 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11)муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны муниципаль хезмәткәр үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү»;

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта)
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин